ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2023 елның 23 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 88 (I өлеш); 2023, № 54 (I өлеш), № 80 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 1 өлешнең 1 пунктында «113 437 813,7» санын «119 866 313,7» санына алмаштырырга, «нуль күрсәткече белән» сүзләрен «6 428 500,0 мең сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең 1 пунктында «97 325 954,5» санын «103 754 454,5» санына алмаштырырга, «нуль күрсәткече белән» сүзләрен «6 428 500,0 мең сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлешнең 1 пунктында «89 432 633,5» санын «95 861 133,5» санына алмаштырырга, «нуль күрсәткече белән» сүзләрен «6 428 500,0 мең сум күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

г) 4 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Ихтимал булган гарантия очраклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен түбәндәгеләр исәбеннән үтәү өчен каралган Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән – 2023 елга 6 103 099,2 мең сум, 2024 елга 5 811 892,3 мең сум һәм 2025 елга 5 534 768,1 мең сум күләмендә;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары исәбеннән – 2023 елга 0,0 мең сум, 2024 елга 161 250,0 мең сум һәм 2025 елга 193 500,0 мең сум күләмендә.»;

д) түбәндәге эчтәлекле 7 өлеш өстәргә:

«7. 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Россия Федерациясе валютасында Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре программасын әлеге Законга $2^1$ нче кушымта нигезендә расларга.»;

2) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ нче кушымта өстәргә:

«2023 елга, 2024 һәм
2025 еллар план чорына
Татарстан Республикасы
бюджеты турында»
Татарстан Республикасы
Законына
$2^1$ нче кушымта

2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына
Россия Федерациясе валютасында
Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре
программасы

1 нче таблица

2023 елда Россия Федерациясе валютасында бирелә торган
Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре исемлеге

| № п/п | Гарантияләү юнәлешләре (максатлары) | Принципал-ларның категорияләре һәм (яисә) исемнәре | Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләренең гомуми күләме (мең сум) | Гарантның принци-палларга карата регресс таләбе хокукы булу | Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен бирүнең һәм үтәүнең башка шартлары |
|---|---|---|---|---|---|
| | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | «Проект финанслауның махсуслаштырылган җәмгыятьләре облигацияләрен кулланып, проектларны финанслау кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясендә региональ үсеш буенча Хөкүмәт комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2020 елның 31 декабрендәге 2459 номерлы Россия | «Татдортранс-инвест» АҖ | 6 428 500,0 | Юк | 1. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе принципалның шартнамә буенча заем (төп бурыч һәм процентлар) бурычын каплау буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә.<br>2. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе принципалның штрафлар, комиссияләр, заемны соңарып каплаган өчен һәм процентларны соңарып түләгән өчен пеняләр, башка түләүләр башкару буенча йөкләмәләрен үтәүне, шулай ук шартнамә буенча башка йөкләмәләрне үтәүне |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Федерациясе Хөкүмәте карары кысаларында проектларны гамәлгә ашыру | | | | тәэмин итми.<br>3. Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе принципалның шартнамә буенча йөкләмәләрен вакытыннан алда үтәүне тәэмин итми, шул исәптән принципалга аларны вакытыннан алда үтәү турында таләп куелган йә принципалның йөкләмәләрен үтәү срогы җиткән дип санала торган вакыйгалар (хәлләр) килеп чыккан очракта.<br>4. Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе буенча субсидиар җаваплылыкка ия. |

2 нче таблица

2024 һәм 2025 елларда
Россия Федерациясе валютасында бирелә торган
Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре исемлеге

| № п/п | Гарантияләү юнәлешләре (максатлары) | Принципал-ларның категорияләре һәм (яисә) исемнәре | Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләренең гомуми күләме (мең сум) | | Гарантның принципалларга карата регресс таләбе хокукы булу | Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен бирүнең һәм үтәүнең башка шартлары |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | 2024 ел | 2025 ел | | |
| | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | - | - | - | - | - | - »; |

3) 6 нчы кушымтаның 2 нче таблицасында:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Башка бюджет ассигнованиеләре | 11 | 1 | 1 | 99 0 00 0741 0 | 00 | 6 938 200,0 | 7 215 700,0» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «шул исәптән: ихтимал булган гарантия очраклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен үтәүгә җибәрелә торган акчалар | 11 | 1 | 1 | 99 0 00 0741 0 | 00 | 161 250,0 | 193 500,0»; |

4) 7 нче кушымтаның 2 нче таблицасында:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «Башка бюджет | 1 | 1 | 99 0 00 0741 0 | 00 | 6 938 200,0 | 7 215 700,0» |

ассигнованиеләре

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «шул исәптән: ихтимал булган гарантия очраклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен үтәүгә җибәрелә торган акчалар | 1 | 1 | 99 0 00 0741 0 | 00 | 161 250,0 | 193 500,0»; |

5) 8 нче кушымтаның 2 нче таблицасында:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «Резерв фондлар | 99 0 00 0741 0 | 00 | 1 | 1 | 6 938 200,0 | 7 215 700,0» |

юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| «шул исәптән: ихтимал булган гарантия очраклары буенча Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләрен үтәүгә җибәрелә торган акчалар | 99 0 00 0741 0 | 00 | 1 | 1 | 161 250,0 | 193 500,0». |

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2023 ел, 24 ноябрь
№ 115-ТРЗ